СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2023 г.Лениногорск № 5

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 17 декабрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында аукционнар үткәрмичә бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләүләре күләмен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 2 өлешенә (19.12.2022 ел редакиясендә), Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 17 декабрендәге 85 номерлы карары белән расланган торглар үткәрмичә генә бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Түбәндәге эчтәлекле 3 бүлек белән тулыландырырга:

«3 2022 һәм 2023 елларда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча ташламалы аренда түләве очракларын һәм мондый түләү күләмен билгеләү.

3.1 2022 һәм 2023 елларда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча ташламалы аренда түләве җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре төзелгән яисә мондый аренда шартнамәсенә карата әлеге аренда шартнамәсенең гамәлдә булу вакытын, әлеге аренда шартнамәсен төзү нигезләренә карамастан, аренда түләве буенча бурыч булмаган очракта билгеләнә.

3.2 Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә өстәмә килешү төзегәндә өстәмә килешү нигезендә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты арта торган вакыт өч елдан арта алмый.

3.3 Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе яисә җир кишәрлеген арендалауның мондый шартнамәсенә өстәмә килешү буенча аренда түләве җир кишәрлегеннән файдалануның түбәндәге төрләре буенча билгеләнә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүенә;
- җитештерү өлкәсе объектлары (сәнәгать, төзелеш (шул исәптән торак төзү), транспорт, элемтә, энергетика һ.б.);
- «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган объектлар төзү өчен;
- Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәваланучы затларны озатып йөрүче гражданнарны вакытлыча түләүсез яшәү өчен билгеләнгән объектлар өчен.

3.4 Аренда түләве күләме бер сумнан да ким була алмый һәм 1 елдан артык вакытка билгеләнә.

3.5 Арендага бирүче торглар үткәрмичә әлеге бүлекнең 3.2 пунктында күрсәтелгән килешүне, арендаторның аны төзү таләбе белән мөрәҗәгать иткән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча төзергә тиеш.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы МКУсына йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Лениногорск
муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г. Хөсәенов